# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасында чит ил инвестицияләре турында"**
**Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм**
**"Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында"**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 26 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында чит ил инвестицияләре турында" 1994 елның 19 июлендәге 2180-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы икенче абзацында (2008 елның 22 гыйнварындагы 6-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1994, № 7; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 7 – 8; 2003, № 9 (II өлеш); 2008, № 1) "һәм" сүзен "яисә" сүзенә алмаштырырга.

**2 статья**

"Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында" 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 12; 2003, № 6; 2005, № 7 – 8; 2009, № 7 – 8 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада "киңәйтүгә," сүзен төшереп калдырырга;

2) 2 статьяның икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Объектларны төзү һәм файдалану Россия Федерациясе законнарына туры килмәсә, аларны инвестицияләү тыела.";

3) 3 статьяның беренче өлешендә "һәм билгеләнгән тәртиптә расланган стандартлар (нормалар һәм кагыйдәләр)" сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 4 статьяның сигезенче өлешендә "ике яисә берничә катнашучының" сүзләрен "арасында төзелә торган шартнамәдә һәм (яисә) дәүләт контрактында башкасы билгеләнмәгән булса, алар ике һәм аннан күбрәк субъектларның" сүзләренә алмаштырырга;

5) 6 статьяның беренче өлешендәге икенче абзацында ", шулай ук билгеләнгән тәртиптә расланган стандартлар (нормалар һәм кагыйдәләр)" сүзләрен төшереп калдырырга;

6) 9 статьяда:

а) "гамәлгә ашыру өчен" сүзләреннән соң "бюджет законнары нигезендә" сүзләрен өстәргә;

б) уналтынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

7) 11 статьяның икенче өлешендә "һәм" сүзен "яисә" сүзенә алмаштырырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2012 елның 17 мае
№ 23-ТРЗ